**«Комиксханә» республикакүләм бәйгесен уздыру турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

1.1. Әлеге нигезләмә **«Комиксханә»** (алга таба – Бәйге) республикакүләм бәйгесен оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Бәйге татар әдәбиятында комикслар форматын киңрәк катлам укучыларга тәкъдим итүне, әлеге юнәлеш белән кызыксынучы авторларны барлауны күздә тота.

1.3. Бәйге түбәндәге бурычларны хәл итә:

– укучыларда әхлакый идеаллар тәрбияләү;
– гаилә традицияләрен саклау һәм үстерү;
– татар әдәбиятында заманча форматларны куллану даирәсен арттыру.

1.4. Бәйге «Ялкын» журналы («ТАТМЕДИА» АҖ филиалы – «Ялкын» журналы редакциясе»), Татарстан Ресбпуликасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә уздырыла. Бәйгенең төп партнерлары:
- «Алдынгылар хәрәкәте»нең Татарстан бүлекчәсе
- Татарстан Республикасы Язучылар берлеге
- Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге.

## 2. Бәйгедә катнашучылар

2.1. Бәйгедә 5-11 сыйныф укучылары аерым яки сыйныф белән бергәлектә катнаша ала.

Балалар эшләрен әзерләү ата-аналар һәм укытучылар ярдәме белән башкарылырга мөмкин.

## 3. Бәйге уздыру тәртибе һәм вакыты турында

3.1. Бәйге 2024 елның 8нче апреленнән алып 2024 елның 31нче ноябренә кадәр үткәрелә.

3.2. Бәйгегә гариза һәм эшләр 08.04.2024 дән алып 30.09.2024 гә кадәр кабул ителә. Гариза үрнәге беркетелгән (Кушымта).

3.3. Эшләрне әзерләү тәртибе:

Бәйгегә түбәндәге эшләр кабул ителә:

- Кулдан ясалып электрон форматка күчерелгән яки турыдан-туры электрон форматта ясалган комикс (жпег, пдф, һ.б.);
- Комиксның күләме А4 форматындагы 6 биттән артмаска тиеш;
- Комикслар 3 номинациядә кабул ителә:
  - **ӘДӘБИ ӘСӘР:** нигезендә татар классик әдәби әсәре яки әкияте

сюжеты булыра тиеш

**- ТАНЫЛГАН ШӘХЕС:** татар язучысының яки танылган шәхесенең тормыш юлын чагылдырган комикслар

**- ИРЕКЛЕ ТЕМА:** мәктәп тормышы, беренче мәхәббәт, минем гаилә, ясалма интеллект мөмкинлекләре, «Ялкын»га 100 ел, милли каһарман, песиләр, дуслык, социаль проблемалар, сәяхәт һ.б.

3.4. Эшләргә бәя бирү критерийлары:

- креативлык;
- сюжетның тотрыклылыгы;
- рәсемнәрнең зәвыклы эшләнеше
- текстларның грамоталылыгы.

3.5. Эшләр татар телендә булырга тиеш

3.6. Бер автордан 3тән артык эш кабул ителми.

3.7. Конкурс тәртибенә туры килә торган эшләр редакция карары белән http://yalkyn.ru сайтында урнаштырылырга мөмкин.

## 4. Бүләкләү

4.1. Бәйгедә катнашучыларның барысына да «Ялкын» журналы тарафыннан бәйгедә катнашу турында электрон сертификатлар җибәреләчәк. Укучы сертификатның кәгазь вариантына да заказ бирә ала, 1 сертификат бәясе – 200 сум.

4.2 Бәйгедә 3 номинациядә дә берничә җиңүче ачыкланачак. Бүләкләр арасында төрле кибетләргә сертификатлар, электрон техника, бәйге өчен махсус әзерләнгән мерч һәм башка кыйммәтле бүләкләр бар. 3 призлы урынны билгеләүдән тыш актив катнашучыларга яки сыйныфка оештыручылар карары белән махсус бүләкләр билгеләнергә мөмкин.

4.3. Җиңүче һәм призерларны бүләкләү вакыты һәм урыны бәйгегә йомгак ясаганнан соң 2024 елның октябрь аенда http://yalkyn.ru сайтында игълан ителәчәк.

## Өстәмә нигезләмәләр

5.1. Бәйгене оештыручылар җиңүчеләрне игълан иткәнче бәйгегә килгән эшләрне үз интернет-ресурсларында, шул исәптән «Вконтакте» төркеменә урнаштырырга хокуклы. Онлайн тавыш бирү нәтиҗәләре бәйгегә нәтиҗә ясаганда исәпкә алынырга мөмкин, тик хәлиткеч роль уйнамый. Бәйгегә үз эшләрен җибәрүчеләр әлеге һәм башка нигезләмәләр белән килешүләрен белдерә.

5.2. Бәйгедә катнашу өчен мөһим шарт: «Ялкын» журналына 2024 елның 2нче яртыеллыгына язылу турында квитанция. Журналга 01.04.2024-15.06.2024 аралыгында язылырга мөмкин.

**Эшләр** yalkin@bk.ru **электрон адресына яки почта аша кабул ителә (420066 г. Казань, ул. Декабристов д.2). Белешмәләр өчен телефон: 8(843)**

**222-06-01, 222-09-84 (1570, 1542), 89172-83-65-45.**

**«Комиксханә» республикакүләм бәйгесе нигезләмәсенә кушымта**

**Гариза**

| | |
|---|---|
| **ФИО:** | |
| **Яшь:** | |
| **Яшәү урыны:** | |
| **Уку урыны, сыйныф:** | |
| **Телефон:** | |
| **e-mail:** | |
| **Җитәкчесенең ФИО:** | |
| **Җитәкчесенең телефоны:** | |
| **Җитәкчесенең e-mail:** | |